Ответы заданий муниципального этапа республиканской олимпиады школьников
по татарскому языку для русскоязычных учащихся
школс обучением на русском языке
2024-25 учебный год, 4 класс

Рус мәктәпләрендә белем алучы рус телле укучылар өчен
татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре җаваплары
2024-25 уку елы, 4 нче сыйныф

Время проведения (Үткәрү вакыты) -120 минут

Максимальный (максималь) балл – 70

**1. Прочитайте слова и подчеркните те слова, в которых имеются приведенные звуки** (в каждой строчке по несколько слов). *(За каждое слово 0,5 б., максимальное количество – 4 балла)*

[къ] – сүзлек, кара, күз, китап, куян, балык, дәреслек, кыңгырау, Казан.
[гъ] – гөл, гади, бәйге, бәрәңге, тегүче, шигырь, багана, көзге, билге.

**2. Распределите слова по нижеприведенным тематическим категориям:**

Идел, яшел, Казан, су, чыпчык, чәй, ипи, соры, чыршы, шәмәхә,сыерчык, кара, кызыл, тавык, ботка, лалә, Чатыр тау, пылау, өчпочмак, чирәм.
*(Максимальное количество – 10 баллов)*

Географик урын – ИДЕЛ, КАЗАН, ЧАТЫР ТАУ

Ашамлыклар – ИПИ, БОТКА, ПЫЛАУ, ӨЧПОЧМАК

Эчемлекләр – СУ, ЧӘЙ

Үсемлекләр – ЧЫРШЫ, ЛАЛӘ, ЧИРӘМ

Кошлар–ЧЫПЧЫК, ТАВЫК, СЫЕРЧЫК

Төсләр– ЯШЕЛ, СОРЫ, ШӘМӘХӘ, КАРА, КЫЗЫЛ

**3. Запишите даты словами.** *(Максимальное количество – 5 баллов)*

1) СИГЕЗЕНЧЕ МАРТ– Халыкара хатын-кызлар көне.

2) БЕРЕНЧЕ СЕНТЯБРЬ– Белем бәйрәме.

3) ЕГЕРМЕ ӨЧЕНЧЕ ФЕВРАЛЬ–Ватан саклаучылар көне.

4) Бүгенге дата– уналтынчы декабрь.

5) Салават күперенең ҖИДЕ төсе бар.

**4. Найдите антонимы к словам.** *(по 1 баллу, макс. количество – 6 баллов).*

яшь –КАРТ биек - ТӘБӘНӘК

тирән–САЙ ела - КӨЛ

якты –КАРАҢГЫ бай - ЯРЛЫ

**5. Задайте вопросы к выделенным членам предложения**. (*Максимальное количество – 3 балла)*

1. Кычыткanda витамин бик күп. НӘРСӘ?
2. Менә без көткән көн дә килде.КЕМ?
3. Ананың йөзе елмая. НИШЛИ?

**6. Придумайте и напишите прилагательные** (*по 0,5 балла, макс.б. – 5).*

Тагын __________ кыш җитте. ____________ көз артта калды. Бар җирне __________ кар каплады. ________ кошлар _____________ җырларын җырламыйлар хәзер. Аларга суык. ___________ җил ___________тавышлар чыгарып исә.

Ә ___________балалар шат. Алар ________ кыштан курыкмыйлар. Балалар ____________ уеннар уйныйлар.

**7. Прочитайте текст и утверждения после него. Если утверждение верное, напишите ӘЙЕ, если не верное, напишите ЮК.***(Максимальное количество – 8 баллов)*

**Куян**

Абый урманга барды. Ул урманнан куян тотып кайтты. Безнең дә кроликларыбыз бар. Куянны кроликлар янына куйсак, нишләр икән? Без куянны кроликлар янына яптык та читтән генә күзәтә башладык. Дуслашып китәләрме, юкмы? Юк шул, дуслаша алмадылар. Нинди кызганыч, бичара!

Бер почмакта тик тора. Без анны кырга алып чыктык та урманга таба җибәрдек. Куян бар көченә чабып китте.

*(НигъмәтИсхаковбуенча.)*

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Куянны мин алып кайттым. | ЮК |
| 2 | Куян кырда яши иде. | ЮК |
| 3 | Куян белән кролик дуслаштылар. | ЮК |
| 4 | Куян белән кроликны бер читлеккә яптык. | ӘЙЕ |
| 5 | Куян бик кызганыч иде. | ӘЙЕ |
| 6 | Куян читлеккә ияләште. | ЮК |
| 7 | Без куянны кире урманга җибәрдек. | ӘЙЕ |
| 8 | Куян акрын гына урманга кереп китте. | ЮК |

**8. Найдите синонимы к выделенным словам.** *(Максимальное количество – 3 балла)*

Өлкәннәргә **ярдәм итәргә** кирәк. БУЛЫШЫРГА

Урамнан **кечкенә** кыз килеп керде. БӘЛӘКӘЙ

Безнең гаилә **дус** яши. ТАТУ

**9. Составьте предложения и запишите.** (*За каждый правильный ответ по 2 балла, максимальное количество – 6 баллов)*

1) китап, яратам, укырга, буш вакытларымда, мин.

МИН БУШ ВАКЫТЛАРЫМДА КИТАП УКЫРГА ЯРАТАМ.

2) еш, китапханәгә, син, барасыңмы?

СИН КИТАПХАНӘГӘ ЕШ БАРАСЫҢМЫ?

3) кичә, бардык, белән, дустым, без, көнгә, туган.

БЕЗ КИЧӘ ДУСТЫМ БЕЛӘН ТУГАН КӨНГӘ БАРДЫК.

**10.Напишите сообщение на тему “Татарстан – мой родной край”.** *(10 предложений, максимальное количество – 20 баллов)*

Ответы заданий муниципального этапа республиканской олимпиады школьников
по татарскому языку для русскоязычных учащихся
школ с обучением на русском языке
2024-25 учебный год, 5 класс

Рус мәктәпләрендә белем алучы рус телле укучылар өчен
татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре җаваплары
2024-25 уку елы, 5 нче сыйныф

Время проведения (Үткәрү вакыты)– 120 минут

Максимальный (максималь) балл – 80

1. **Запишите перевод слова на русский язык и количество букв, звуков.** (*Максимальное количество 10 баллов)*

Белем – ЗНАНИЕ, 5 хәреф, 5 аваз.

Сәгать –ЧАСЫ, 6 хәреф, 5 аваз.

Яңалык –НОВОСТЬ, 6 хәреф, 7 аваз.

Көндәлек –ДНЕВНИК, 8 хәреф, 8 аваз.

Яхшы – ХОРОШО/ ХОРОШИЙ, 4 хәреф, 5 аваз.

*2.* **Сколько раз и в скольки словах в стихотворении встречается звук [о]?***(Максимальное количество – 2 балла).*

Туган ил ул – алтын арышлар,

Туган ил ул – зифа камышлар,

Туган ил ул – иркен болыннар,

Болыннарда нәни колыннар. *(Зәкия Туфайлова)*

Ответ: 6

3. **Составьте слова с помощью корня и суффикса.**(*Максимальное количество 6 баллов)*

*Слова (сүзләр): балык, дәрес, акыл, сыйныф, дүрт, бәхет.*

*Суффиксы (кушымчалар): -лы, -лек, -чы, -лык, -таш, -ле*

БАЛЫКЧЫ, ДӘРЕСЛЕК, АКЫЛЛЫ, СЫЙНЫФТАШ, ДҮРТЛЕ, БӘХЕТЛЕ

4. **Прочитайте текст. Определите жанр текстов.***(Максимальное количество – 6 баллов)*

1) Борын-борын заманда булган икән, ди, бер патша. Бу патшаның булган, ди, өч кызы. Патша кызлары берсеннән-берсе матур булганнар, ди. Көннәрдән-беркөнне бу өч кыз болынлыкка йөрергә дип чыкканнар. Болар болынлыкта йөргән вакытта гына бик каты җил-давыл чыга да шул җил-давыл бу кызларның өчесен дә күтәреп алып китә.

ӘКИЯТ

2) Эш беткәч, уйнарга ярый.

МӘКАЛЬ

3) Утта янмый, суда батмый.

ТАБЫШМАК

Сайлап алу өчен сүзләр: табышмак, мәкаль, әкият.

**5. Запишите предложения в таком порядке, чтобы получился текст.***(Макс. количество – 9 баллов.)*

| Җөмлә | Тәртип саны |
|---|---|
| Безне шатланып каршы алдылар. | 3 |
| Әби самовар куйды. | 4 |

| | |
|---|---|
| Ашап бетергәч, әбигә рәхмәтләр әйттек. | 8 |
| Әби күчтәнәчләр биреп, безне озатып калды. | 9 |
| Кышкы каникуллар башланды. | 1 |
| Самовар җырлый-җырлый өстәлгә килеп басты. | 5 |
| Без үзебезне өстәл артында бик әдәпле тоттык. | 7 |
| Мин энем Рөстәм белән кышкы каникулда әбиләрдә кунакта булдым. | 2 |
| Самовар артыннан ит сумсалары, алма, конфетлар, хуш исле бал өстәлгә куелды. | 6 |

**6.Допишите пропущенные слова.**(*по 1 баллу, макс. количество – 10баллов).*

**Кыш**

Салкын кыш ҖИТТЕ. Җир өстен ак кар КАПЛАДЫ. Елгалар калын боз белән КАПЛАНДЫ. Көннәр КЫСКАРДЫ, ә төннәр ОЗЫНАЙДЫ. Хәзер инде кошлар да матур итеп ҖЫРЛАМЫЙЛАР. Алар җим ЭЗЛИЛӘР. Балалар саф һавада гөр килеп УЙНЫЙЛАР. Табигать ялга кадәр бераз ЯЛ ИТӘ.

Мин кышны ЯРАТАМ.

**7. Прочитайте и озаглавьте текст. С каким вариантом утверждения вы согласны?** *(1 балл за озаглавление, по 1 баллу за одно утверждение, макс. б. – 7).*

*ЧЫРШЫ БИЗӘҮ*

Тиздән чыршы бәйрәме якынлаша. Безнең бик матур чыршыбыз бар. Без абыем белән чыршы бизәргә тотындык. Әнием дә бизәште. Чыршының ботакларына йолдызлар, ялтыравыклы шарлар, тасмалар элдек. Шуннан соң абыем җепкә тезелгән төрле төстәге вак лампочкалар белән чыршыны уратып куйды. Лампочкалар янгач, чыршы ялт итеп балкып китте. Мин бик шатландым.

Чыршыбыз бик матур, ямь-яшел. Әнием дә, дәү әнием дә чыршыны күреп, бик сокландылар. Песи дә килде. Ул алгы тәпиләре белән чыршының ботакларын тотып-тотып карады.

*(Габдулла Гомәров)*

| | | |
|---|---|---|
| Текст Яңа елга әзерлек турында. | **Әйе** | Юк |
| Чыршыны үзем генә бизәдем. | Әйе | **Юк** |
| Чыршының ботакларына ай, кояш элдек. | Әйе | **Юк** |
| Этебез дә чыршыны ошатты. | Әйе | **Юк** |
| Безнең чыршыбыз бик матур булды. | **Әйе** | Юк |
| Без гаиләдә ике бала. | **Әйе** | Юк |

**8. Спросите у друга на татарском языке** *(максимальное количество – 8 баллов)*.

1) – как он себя чувствует

ҮЗЕҢНЕ НИЧЕК ХИС ИТӘСЕҢ?//КӘЕФЕҢ НИЧЕК?

2) – посмотрел ли он этот фильм

СИН БУ ФИЛЬМНЫ КАРАДЫҢМЫ?

3) – придет ли он завтра в школу

СИН ИРТӘГӘ МӘКТӘПКӘ КИЛӘСЕҢМЕ?

4) – есть ли у него домашние животные

СИНЕҢ ЙОРТ ХАЙВАННАРЫҢ БАРМЫ?

**9. Из данных слов составьте и запишите пословицу.** (*Максимальное количество –2 балла)*

курыксаң, барма, урманга, бүредән

*БҮРЕДӘН КУРЫКСАҢ, УРМАНГА БАРМА.*

**10. Составьте и напишите продолжение рассказа**(*по 2 балла за одно предложение, макс. б. – 20*).

Мин туган ягымны бик яратам.

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

**Рус мәктәпләрендә белем алучы рус телле укучылар өчен**
**татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры**
**биремнәренең җаваплары**
**2024-25 уку елы, 6 сыйныф**

**Максималь балл - 74**

1. **Придумайте название рисунку (3 балла) и составьте 3 вопроса (*максимальный балл – 12)***

**2. Отгадайте загадку *(максимальный балл – 4)*.**

*Икмәк*

**3. Напишите антонимы *(максимальный балл – 5)*.**

*1) килә – **китә***

*2) көн – **төн***

*3) ял – **эш***

*4) файдалы – **зарарлы***

*5) ачыла – **ябыла***

***4. Напишите пропущенные слова (максимальный балл – 6).***

*Кышкы тынлык*

*Болыт йоклый **<u>күгендә</u>**,*

*Аю йоклый **<u>өнендә,</u>***

*Балык – **<u>елга</u>** төбендә ...*

*Җилләр үтә сак кына,*

*Басып бик йомшак кына*

*Черем итәр чак кына.*

**5. Переведите предложения *(максимальный балл – 14)*.**

*1) Ул хастаханәдә эшли.*

*2) Ул хатларны еш ала //Ул хатлар еш ала.*

*3) Иртәгә миңа шалтыратырга онытма.*

*4) Быел декабрь җылы һәм карсыз.*

*5) Син мәктәпкә берчайчан да соңга калмыйсыңмы?*

*6) Гадәттә ул эшкә җәяү йөри.*

*7) Син берничә конфет ала аласың./ Сиңа берничә конфет алырга мөмкин.*

**6. Предложения разбиты на части. Поставьте слова в правильном порядке и запишите *(максимальный балл – 10)*.**

*1) Япониядә уку елы сентябрьдә түгел, апрельдә башлана.*

*2) Җәйге каникул аларда бер ай гына.*

*3) Япониядә урта белем алу 3 ел эчендә бара.*

*4) Дәүләт мәктәпләрендә кызлар белән малайлар бергә белем ала.*

*5) Укучылар 15 яшьтән мәктәптә читтән торып укый ала.*

**7. Допишите окончания слов в предложениях (за каждый верный ответ – 0,5 балла, мак.б. - 3).**

*1) Татарстан гербындагы канатлы барс нәрсә**не** аңлата?*

*2) Барс – борынгы Болгар дәүләт**е//енең** билгесе.*

*3) Элек бу җир**ләрдә** Барс кабиләләре яшәгән.*

*4) Халык аны үз әкият**ләренд**ә канатлы итеп сурәтләгән.*

*5) Барс ирек**не** ярата, читлек**тә** яши алмый.*

**8. Переведите рекламные слоганы *(максимальный балл – 5)*.**

*1) «Россия – киң//юмарт күңел/күңелле»*

*2) «Бар да/ Барысы да яхшы булачак»*

*3) «Илнең бөтен/барлык юлларында»*

*4) «Без сезнең турында кайгыртабыз»*

*5) «Танклар пычрактан курыкмый»*

**9. Напишите про свой идеальный день рождения *(за каждое верное предложение – 3 балла, максимальное количество баллов – 15)*.**

**Рус мәктәпләрендә белем алучы рустелле укучылар өчен**
**татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры**
**биремнәренең җаваплары**
**2024-25 уку елы, 7 сыйныф**

**Максимальное количество баллов – 85**

**1. Предложения разбиты на части. Поставьте слова в правильном порядке и запишите *(максимальный балл – 8)*.**

*1) Казан шәһәре урнашкан җир янында тау булган.*

*2) Бу тау башында бик күп еланнар һәм аларның патшасы Зилант яшәгән.*

*3) Кешеләр бу тау янына якын килергә курыкканнар.*

*4) Хан еланнарны юк итәргә куша.*

**2. Прочитайте и озаглавьте текст. Напишите пропущенное слово.**
*(максимальный балл – 3).*

***<u>Беренче кар</u>***

**3. Вставьте пропущенные компоненты фразеологизмов** *(максимальный балл – 8).*

*1)* ***күз*** *ачып йомганчы; 2) авызга* ***су*** *кабу; 3)* ***тел*** *йотарлык; 4)* ***дүрт*** *күз белән; 5)* ***авыз*** *ачып калырга; 6)* ***баш*** *әйләнә; 7) башы* ***күккә*** *тию; 8) алтын* ***куллы***

**4. Напишите советы к представленным ситуациям** *(максимальный балл – 10).*

*1) Мин бернәрсә дә аңламадым/ Яңадан сора.*

*2) Минем ашыйсым килә/ Ашханәгә кер.*

*3) Бүген көн салкынча һәм җилле/ Урамга чыкма/ Өйдә китап укы.*

*4) Мин телефонны югалттым/ Кая булганыңны искә төшер/ Паникага бирелмә.*

*5) Иртәгә төрек теле буенча олимпиада/ Иртәрәк ят/ Ял итәргә тырыш.*

**5. Переведите предложения** *(максимальный балл – 12)*.

*1) Ул заманча кием матур һәм уңайлы дип саный.*

*2) Бу юл ябык.*

*3) Ул берничә сүзне генә аңлады.*

*4) Сөт сәламәтлек өчен файдалы.*

*5) Сезгә бу журналларны өйгә алырга рөхсәт иттеләрме?*

*6) Монда светофор юк һәм юл киселеше бик куркыныч урын.*

**6. Напишите пропущенные антонимы в пословицах *(максимальный балл – 10)*.**

*1) **Иртәнге** ашны ташлама, **кичке** ашны башлама.*

*2) **Батыр** ут булыр, **куркак** юк булыр.*

*3) **Аз** сөйлә, **күп** тыңла.*

*4) **Акыллы** әйтер — юл куйдым, **ахмак** әйтер — җиңдем.*

*5) Тычканга **үлем**, мәчегә **көлке**.*

**7. Переведите слоганы (*максимальный балл – 4*).**

*1) «Барысын да дөрес эшләдең!»*

*2) «Яхшыга/Әйбәткә күч»*

*3) «Барысы да шоколадта булачак»*

*4) «Тормышны яхшыга үзгәртәбез»*

**8. Допишите окончания в предложениях (*за каждый верный ответ по 0,5 балла, максимальный балл – 5*).**

*1) Кыш башлангач, укытучы бала**ларга** кош**лар** өчен җимлек ясап куярга кушты.*

*2) Бала**лар** җимлек**кә** ярма, икмәк валчык**лары** һәм коры миләш салдылар.*

*3) Алар үзләре дә миләш**не** бик яраталар иде.*

*4) Көз көне җыйган миләш**нең** кош**ларга** кирәге чыкты.*

*5) Һәр көн иртән бала**лар** җимлек**кә** яңа җим салалар.*

**9. Переведите и составьте предложения *(максимальный балл – 10)*.**

*1) Иртәнге сигез. Дәрес иртәнге сигездә.*

*2) Тугыз тулырга унбиш минут. Автобус тугыз тулырга унбиш минут кала килде.*

*3) Унберенче ярты. Унберенче яртыда тәмамлыйбыз.*

*4) Унбер тулып ун минут/ Уникенче ун минут. Унбер тулып ун минутка кадәр көттек.*

*5) Ун сәгать унбиш минут/ Унберенче унбиш минут. Хәзер ун сәгать унбиш минут.*

**10. Напишите историю жизни вашего любимого писателя. (за каждое верное предложение – 3, максимальный балл – 15).**

**Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең рус төркемендә укучылар өчен татар теленнән үткәрелә торган муниципаль тур олимпиада биремнәре ачкычы**
**2024-2025 уку елы, 8 нче сыйныф**

**Максималь балл – 80**

**1. Задания по картине. (12 баллов, по 2 балла за каждый правильный ответ)**
Көтеп алган сәяхәт. Көзге каникул җиткәч, гаилә сәяхәткә җыенды. Гаиләдә дүрт кеше бар. Көзге салкын, җилле көн. Гаилә самолетка утырырга ашыга. Әти зур зәңгәр чемоданны тартып бара.
**2. Выберите правильный вопрос к выделенному слову. (1 балл)**
А) кая?
**3. Вместо точек выберите нужное слово. (1 балл)**
Б) чөнки
**4. Выберите правильный перевод. (1 балл)**
А) Дәресләр беткәч, мин өйгә киттем.
**5. В какой последовательности необходимо поставить словосочетания, чтобы получилось предложение? (2 балла)**
1) Ә, Б, В, А
**6. В какой последовательности нужно расставить предложения, чтобы получился текст? (4 балла)**
5) Д, Б, Г, А, Ә, В
**7. Составьте предложения с словосочетаниями. (12 баллов, по 2 балла за каждый правильный ответ)**
Кара итәк, ак блузка киеп концертка бардык. Әни улына ак юл теләде. Күкне кара болыт каплады. Бала әнисенә ак бәхет теләде. Телефонда кайбер кешеләрне кара исемлеккә кертергә була. Күршебездә аксакал яши.
**8. Прочитайте текст, по содержанию текста в таблице ставьте “+” или “-”. (9 баллов)**

| № | Җөмләләр | Әйе | Юк |
|---|---|---|---|
| 1. | Актив мавыгуларга барлык спорт төрләре дә керми. | | + |
| 2. | Йөзү, ат спорты, ату, теннис – актив спорт төрләре. | + | |
| 3. | Альпинизм, парашют спорты, серфинг, паркур - экстремаль спорт төрләре, алар белән бөтен кеше дә шөгыльләнә алмый. | + | |
| 4. | Бию ябыгу өчен файдалы. | + | |
| 5. | Ял вакытын файдасыз итеп үткәрергә теләсәң, роликларда йөрергә була. | | + |
| 6. | Табигатькә походка чыгу экстрималь ял итү дип санала. | | + |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7. | Сәяхәт итү - күңел ачу гына түгел, ә дөньяны танып белү мөмкинлеге дә. | + | |
| 8. | Караоке актив ял итү төренә керә. | | + |
| 9. | Иҗат итү кешене тынычландыра. | + | |

**9. Допишите окончания слов в предложениях. (14баллов)**

| № | Предложения | **Баллы** (макс.) 14) | **Сумма** (фактич.) ( ) |
|---|---|---|---|
| **1.** | Экстрималь мавыгулар барлык кешеләр***гә*** дә туры килми, моның өчен үзенчәлекле характер кирәк. | 1 | |
| **2.** | Бию кызлар***ның*** үзбәясе***н*** арттыра. | 2 | |
| **3.** | Роликлар***да*** яки велосипед***та*** йөрү, тимераяк***та*** яки чаңгы***да*** шуу сәламәтлек өчен файдалы. | 4 | |
| **4.** | Башка шәһәрләр***гә*** һәм илләр***гә*** баргач, күп кенә яңалыклар***ны*** белергә була. | 3 | |
| **5.** | Сәяхәт***тә*** алган белемнәр***не*** дуслар яки танышлар белән уртаклашырга мөмкин. | 2 | |
| **6.** | Компьютер***да*** музыкаль әсәрләр иҗат итү пассив хобби төре***нә*** керә. | 2 | |

**10. Используя содержание текста 8-го задания, составьте диалог из 12 реплик. (24 балла, по 2 балла за каждую правильную реплику)**

- Дустым, син нәрсә белән мавыгасың?
- Мин спорт белән шөгыльләнәм.
- Спорт белән белән шөгыльләнү актив мавыгу төренә керәме?
- Әйе, йөзү, ат спорты, ату, теннис – актив спорт төрләре.
- Ә экстрималь спорт төрләренә нәрсә керә?
- Альпинизм, парашют спорты, серфинг, паркур - экстремаль спорт төрләре, алар белән бөтен кеше дә шөгыльләнә алмый.
- Ни өчен бөтен кеше дә шөгыльләнә алмый?
- Экстрималь спорт белән шөгыльләнү өчен үзенчәлекле характер кирәк һ.б.

**Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең рус төркемендә укучылар өчен татар теленнән үткәрелә торган мәктәп туры олимпиада биремнәре ачкычы**
**2024-2025 уку елы, 9 нчы сыйныф**

**Максималь балл – 98**

**1. Озаглавьте картину. Составьте 5 словосочетаний по картине. (12 баллов, по 2 балла за каждый правильный ответ)**

Нәни фотограф.

Акыллы бала, җәйге көн, матур пейзаж, кызыклы поход, рәхәт ял.

**2. Задания по тексту.**

**А) Озаглавьте текст. Разделите текст на микротемы (составьте план). (14 баллов, по 2 балла за каждый правильный ответ)**

Минем мавыгуларым.

1. Һәр кешенең үз мавыгулары бар.
2. Мин фотога төшерергә яратам.
3. Мин рәсем ясарга яратам.
4. Мин балачактан биим.
5. Мин укырга яратам.
6. Мин спорт белән шөгыльләнәм.

**Б) Запишите антонимы выделенных слов в предложениях №№ 1, 2, 9, 10, 21. (10 баллов, по 2 балла за каждый правильный ответ)**

Мөһим- әһәмиятсез, эчке – тышкы, элек – хәзер, матур – ямьсез, уңай – тискәре.

**В) В первом и втором абзацах текста найдите и запишите слова, которые являются синонимами к словам: 1) *үзенчәлекле,* 2*) вакыт.* (4 балла, по 2 балла за каждый правильный ответ)**

Уникаль, мизгел.

**Г) Допишите недостающиеся окончания слов в предложениях (10 баллов, по 2 балла за каждый правильный ответ)**

Балачак***та*** бабамнан мирас булып калган иске "Зенит" фотоаппараты бар иде. Мин анда тормыш***ның*** кызыклы мизгелләр***ен***, пейзажлар төшердем. Элек сәнгать мәктәбе***нә*** йөрдем. Рәсем ясаганда, тулысынча иҗат***ка*** чумам һәм вакыт***ның*** ничек узуын сизмим. Шулай ук мин күп вакытым***ны*** уку***га*** багышлыйм. Кайвакыт мин шигырьләр язам һәм дуслары***ма*** укып күрсәтәм.

**Д) Дополните предложения №№ 3, 7, 12, 14, 15, 22 так, чтобы совпадали со смыслом текста. (10 баллов, по 2 балла за каждый правильный ответ)**

Берәүләр - китап укырга, икенчеләр - рәсем ясарга, өченчеләр сәяхәт итәргә ярата. Киләчәктә уңышлы фотограф булырга телим, шуңа күрә курсларга язылдым. Мин майлы буяу, акварель, акрил белән рәсем ясый беләм, ләкин каләм белән ясалган рәсемнәрем уңышлырак килеп чыга. Хип-хоп, дэнсхолл, джаз-фанк кебек заманча биюләр белән шөгыльләнәм, шулай

ук халык биюләрен дә яратып башкарам. Дусларым иҗатымны уңай бәялиләр һәм китап бастырырга киңәш итәләр.

**Е) Переведите шестой абзац. (10 баллов, по 2 балла за каждое правильное предложение)**

Көн саен иртәнге аш алдыннан мин йөгерү белән шөгыльләнәм. Безнең йорт янында зур парк бар. Иртә - моның өчен идеаль вакыт: паркта кешеләр бөтенләй юк диярлек, һавада җиңелчә томан тора, үз-үзең һәм үз фикерләрең белән ялгыз калырга мөмкинлек бар. Парк бик матур, анда карт агачлар күп, кечкенә күл бар. Спорт белән шөгыльләнүче кешеләр тормышта уңышка ешрак ирешә дип мәкаләдә укыдым.

**Ж) Используя содержание текста, составьте диалог из 14 реплик. (28 баллов, по 2 балла за каждую правильную реплику)**

- Кешеләр нәрсәләр белән мавыгалар?
- Берәүләр - китап укырга, икенчеләр - рәсем ясарга, өченчеләр сәяхәт итәргә ярата.
- Дустым, синең яраткан мавыгуың бармы?
- Әйе, бар. Мин фотога төшерергә яратам.
- Фотога нәрсәләр төшерәсең?
- Кызыклы вакыйгаларны, табигать күренешләрен төшерәм. Һ.б.

Ответы муниципального этапа республиканской олимпиады школьников
по татарскому языку для русскоязычных учащихся
школ с обучением на русском языке
2024-25 учебный год, 10 класс

Рус мәктәпләрендә белем алучы рус телле укучылар өчен
татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры
биремнәре җаваплары. 2024-25 уку елы, 10 сыйныф

Время проведения (Үткәрү вакыты) – 180 минут

Максимальный (максималь) балл – 85 балл

**1.Озаглавьте картину (2 б.).**
**Составьте 5 вопросительных предложений по картине (по 3 балла за каждое предложение, макс. б. - 15).**



*Мәрхәмәтлелек// Кешелеклелек//Ярдәм кулы*

1. *Рәсемдә кемнәрне һәм нәрсәләрне күрәсез?*
2. *Ничек уйлыйсыз: рәсемдәге кешеләр танышлармы?*
3. *Ир кеше ни өчен җирдә ята?*
4. *Кыз кемгә шалтырата дип уйлыйсыз?*
5. *Бу вакыйга кайчан һәм кайда булган?*

2. **К словосочетаниям присоединяйте окончания и с ними составьте предложения** (За каждое правильное словосочетание и правильно составленное предложение по 2 балла (1+1), **макс. б. – 6).**

| **Нәрсәне?** | **Кая?** | **Кайда?** |
|---|---|---|
| Сөембикә манарасыН | Сөембикә манарасыНА | Сөембикә манарасыНДА |

1. *Күп шәһәрләрдән туристлар нәкъ менә Сөембикә манарасын күрер өчен килә.*
2. *Татар халкында Сөембикә манарасына багышланган риваятьләр күп.*
3. *Сөембикә манарасында шул чорның архитектура үзенчәлеге чагылыш таба.*

---

**3. Среди слов, приведенных в скобках, найдите правильный вариант и подчеркните** (по 2 б, макс. -10) .

1). Урмандагы алан (кебек, буйлап, дип) Керпе бара. 2). Кая (карама, күрмә, тыңлама), кыштырдавык яфраклар. 3). Аяк асты, бөтен тирә-як сары, кызгылт (агачлар, ботаклар, яфраклар) белән түшәлгән. 4) Калын итеп түшәлгән яфрак (келәм, идән, җир) өстеннән баруы кызык та, рәхәт тә. 5). (Язның, җәйнең, көзнең) шушындый җылы, вак яңгыр сибәләп торган вакытын ярата Керпе. (Ф.Сафиннан)

**4. Подчеркните пословицу, состоявшую только из твердых гласных** (3 балла).

1) Курыккан эт койрыгын кысар.
2) Батыр үз халкын яклый.
**3) Батырларга юл туры.**

**5. Переведите текст на русский язык** (за каждую фразу по 1б., макс. 5 б.).

1. Так нельзя.
   *Болай//Алай ярамый*
2. С Днем Победы, дорогие ветераны!
   *Кадерле ветераннар, Җиңү көне белән!*
3. Что случилось?
   *Нәрсә//Ни булды?*
4. Добрый день, уважаемые друзья!
   *Хәерле көн, хөрмәтле дуслар!*
5. Доброго пути!
   *Хәерле юл!*
6. Как твои дела?

*Эшләрең//Хәлләрең ничек?*

7. Дайте, пожалуйста, словарь?
   *Сүзлек бирегезче//бирегез әле?//Сүзлек бирегез әле, зинһар?*
8. Да, конечно, можно!
   *Әйе, билгеле , мөмкин!//Әйе, мөмкин, билгеле!*

9. Переведите, пожалуйста?
   *Тәрҗемә итегез, зинһар?//Тәрҗемә итегезче?//Тәрҗемә итеп бирегезче?*
10. К сожалению, я не знаю.
   *Кызганычка каршы, мин белмим шул.*

**6. Прочитайте текст и выполните задания по тексту.**

Туган илне сагыну дигән хис тә төрле дәрәҗәдә, төрлечә була икән. Менә син чит ил урамнарында ялгыз йөреп кара. Шагыйрь әйтмешли, син кем кадерлесе анда? Кинәт авырдың, ди. Докторга күренү өчен, күпме доллар кирәк? Синең өчен анда беркем дә җавап бирми, син анда берәүгә дә кирәк түгел. Чит дөньяның иң эре башкаласында, иң зур урамның уртасында син – ком бөртеге. Ватан дигән газиз җирне әнә шунда син бөтен нечкәлеге белән аңлый башлыйсың. Мин бу хисне күп тапкырлар дөньяның күп калаларында кичердем. Бу хис Римда, Тегеранда, Каһирәдә, Истанбулда, Коломбода, гомумән, бер җирдә дә минем күңелемнән китмәде. Чын сагыну үзен шунда танытты.

Безнең авылда яшьлеген Уральск шәһәрендә уздырган тегүче Гатият абзый бар иде. Ул заманында Тукайлар, Кариевләр белән таныш булган. Шул абзый сөйли торган иде: “Чит җирләрдә шунысы читен: үз авылыңның су буендагы ташына кадәр сагынасың”. Без, малайлар, аннан көлә идек. Су буендагы чыпчык ташын кем сагынсын? Ләкин без ашыгыбрак көлгәнбез. Гатият абзыйның бу сүзләрен мин хәзер яхшы аңлыйм.

Һәркемнең үз балачагы, үз шәһәре, үз авылы, үз чишмәләре, үз таулары бар. Һәркем дөньяда безнең шәһәрдән, авылдан, чишмәдән, таудан да матур урын юк дип ышанып яши бирә.

Җир шарында алты кыйтга бар һәм алар һәрберсе үзенчә матур. Әмма иң матуры, әлбәттә, син туган, син үскән җир.

(*М.Мәһдиев*)

**6.1. Придумайте название текста (4 б.) Назовите смысловые абзацы текста (по 2 б., макс. б. - 8).**

*Туган илдән читтә//Чит илдә*

**1).** *Чит җирдә туган ил сагындыра*

**2).** *Гатият абыйның күңелендәге сагыну*

**3).** *Һәркемнең үзенеке*

**4).***Иң матур, иң рәхәт җир –үз җирең*

**6.2. Определите, какие из перечисленных утверждений являются правильными (+), а какие ошибочными (-)? (По 1 б., макс. б.- 8).**

***1). Хикәядә авторның туган илен сагынуы турында язылган. +***

***2). Туган илне сагыну хисе барлык кешеләрдә дә бер төрле була. -***

***3). Авылдашым Гатият абый Тукайны да Габдулла Кариевны да белгән.+***

***4). Малайлар Гатият абый күңелендә яшәгән сагыну хисен яхшы аңлыйлар. -***

***5). Елга буендагы ташны да сагынып була шул.+***

***6). Балачак һәркемнең үзенеке.+***

***7). Җир шарының барлык урыннары да күңелгә якын. -***

***8). Туган җирне генә чын сагыну белән сагынып була.+***

**6.3. Подчеркните предложение, в котором есть фразеологизм и переведите (макс.б. -4)**

1) Син кем кадерлесе анда?
2) Ул заманында Тукайлар, Кариевләр белән таныш булган.
3) Син чит ил урамнарында ялгыз йөреп кара.
4) Бу хис бер җирдә дә минем күңелемнән китмәде.

**6.4. Изложите в 8 - 10 предложениях суть отрывка из текста.**

Һәркемнең үз балачагы, үз шәһәре, үз авылы, үз чишмәләре, үз таулары бар.

(по 2 б., макс. б. – 20)

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

Ответы муниципального этапа республиканской олимпиады школьников
по татарскому языку для русскоязычных учащихся
школ с обучением на русском языке
2024-25 учебный год, 11 класс

Рус мәктәпләрендә белем алучы рус телле укучылар өчен
татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәренә җаваплар
2024-25 уку елы, 11 сыйныф

Время проведения (Үткәрү вакыты) – 180 минут

Максимальный (максималь) балл – 94

**1. Озаглавьте картину (5 баллов). Составьте 5 вопросительных предложений по картине (по 2 балла = 10 баллов). Макс. 15 баллов.**



*Кайгыртучанлык//Мәрхәмәтлелек// Рәхмәт хисләре*

*1.Әлеге рәсемдә кемнәрне күрәсез?*

*2. Бу очрашуның урыны  кайда?*

*3. Әбинең халәте нинди?*

*4. Егет үзенең әбисе белән сөйләшеп утырамы?*

*5. Әби ни өчен өендә түгел?*

2. **Какой послелог нельзя использовать в предложении? По 1 баллу за каждый правильный ответ, макс. б.-3**

А.  Мәктәпкә Айдардан ... кеше килмәде.

1) башка          3) бүтән

2) тыш              **4) белән**

Ә. Илдар сөт ... ак күгәрчен күрде.

1)  кебек         3) тикле

**2) өчен**           4)сыман

Б. Башта урманга ... бар.

**1) саен**            3)тикле

2) кадәр          4)хәтле

3. **Прочитайте текст. Преобразуйте слова, написанные заглавными буквами в конце строк, чтобы они грамматически соответствовали содержанию текста, по 1 балла, макс. б. – 8.**

| | |
|---|---|
| ЕЛНЫҢ иң соңгы ае – декабрь. | ЕЛ |
| Декабрь елны тәмамлый,КЫШНЫ   башлый. | КЫШ |
| ЕЛГАЛАРДА, күлләрдә  боз калыная. Кышкы боз ышанычлы. | ЕЛГА |
| Боз ӨСТЕНДӘ  балыкчылар утыралар. | ӨС |
| Алар боз астыннан балык ТОТАЛАР | ТОТАРГА |
| Декабрьдә чуртан, алабуга ЭЛӘГӘ. . | ЭЛӘГЕРГӘ |
| Балыклар һава ТОРЫШЫНА  бик сизгер . | ТОРЫШ |

| | |
|---|---|
| Көчле суыкларда һәм салкын ҖИЛЛЕ көндә балык аз эләгә. | ҖИЛ |

**4. В какой последовательности необходимо поставить выражения, чтобы получилось предложение? (4 б.)**

А) акыл табылмас

Ә) акыл белән

Б) алтын табылса да

В) алтын белән

1) Ә, Б, В, А 2) Б, А, В, Ә 3) А, В, Б, Ә **4) Б, Ә, А, В**

**5. Переведи на татарский язык и запиши (по 2 б., макс.б.- 14).**

**1.**Когда-то ветер, вода и правда были друзьями. **2.** И однажды правда и вода спросили у ветра: “ Скажи, друг, вот ты очень быстрый и бродишь по всему миру, скажи, когда понадобишься, где тебе найти?” **3. “**Вы найдете меня между гор”. **4.** Тогда ветер и правда спросили у воды, где ее найти в нужный момент. 5**.** “Вы найдете меня в фонтанах, реках и океанах”, - сказала вода. 6. И в конце вода и ветер спросили у правды: “ Где тебя, правда, найти в нужный момент?” 7. А она ответила: “Я должна быть всегда среди людей, ищите среди людей”.

| № | **Предложения** | **Баллы** (макс.) ( 14 ) | **Сумма** (фактич.) ( ) |
|---|---|---|---|
| 1. | *Кайчандыр җил, су һәм хакыйкать (дөреслек) дус булганнар* | ***2*** | |
| 2. | *Һәм көннәрдән беркөнне хакыйкать һәм су җилдән сораганнар: “ Менә син, дускай, бик җитез, бөтендөнья буйлап йөрисең (дөнья гизәсең), әйт әле,* | ***2*** | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | *кирәк чакта сине кайдан табарга?”* | | |
| 3. | *“Сез мине таулар арасыннан табарсыз”* | ***2*** | |
| 4. | *Шунда җил һәм хакыйкать судан кирәк чакта аны кайдан табарга була икәнен сораганнар.* | ***2*** | |
| 5. | *“ Сез мине фонтаннарда, елгаларда, океаннарда табырсыз”, - дигән су.* | ***2*** | |
| 6. | *Һәм азактан су һәм җил хакыйкатьтән сораганнар: “Хакыйкать, кирәк чакта сине кайдан табарга?”* | ***2*** | |
| 7. | *Ул “ Мин һәрвакыт кешеләр арасында булырга тиеш, кешеләр арасыннан эзләгез”, - дип җавап биргән.* | ***2*** | |

**6. Впиши начало предложений (по 2 б., макс.б. – 10).**

1. ... , мин анда бара алмыйм. 2. ... , син барырга тиеш идең. 3. ..., мәктәптән соң, алар еш паркка бара иделәр. 4. ... , аның сиңа шәһәрне күрсәтәсе килә. 5. ..., малайлар тиз генә чишенеп, суга сикерделәр.

| № | **Предложения** | **Баллы** (макс.) (10 ) | **Сумма** (фактич.) ( ) |
|---|---|---|---|
| *1.* | *Эшләрем бетмәсә, ...* | **2** | |
| *2.* | *Минем белүемчә, ...* | **2** | |
| *3.* | *Ялгышмасам, ....* | **2** | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| *4.* | *Минемчә, ...* | **2** | |
| *5.* | *Елгага килеп җитүгә, ...* | **2** | |

**7. Прочитай текст. Выполни задания по тексту**

Батыр кешеләрнең тормышлары турында укыганда, йөрәкләребез ялкынлана, күңелдә хыяллар уяна.

Ә бүгенге көндә батырлык эшләп буламы соң? Әйдәгез, бу сорауга җавап биргәнче, батырлыкның нәрсә икәнлеге турында уйланып алыйк әле. Минемчә, батыр булу өчен күп нәрсә кирәкми кебек. Батыр булу өчен беренче шарт - куркак булмау. Ә куркак булмау өчен кешегә нинди сыйфатлар кирәк?

.... Кайвакыт үз кимчелегеңне, үз ялгышыңны тану башкаларның гаделсез гамәлләрен йөзенә бәреп әйтүгә караганда да авыррак була. Үзебезнең ялгышуыбызны аңлау, аны күтәрә белү өчен шактый көч сорала. Моның өчен куркак булмау кирәк. Чөнки үз ялгышыңны таныдыңмы – аны төзәтергә кирәк. Ә кимчелекләреңнән арыну – ай-һай авыр эш.

... Куркак булмауның тагын бер ягы – кешеләргә ышану. Кешеләргә ышанмаган кеше һичкайчан да зур эшләр эшли алмый. Чөнки ул үзенең эшен бәяли алмаслар, кылган яхшылыгым күмелеп калыр дип курка.

Инде тагын бер мөһим сыйфатка тукталып үтик. Ул – кешелеклелек. Дөньядагы барлык матур эшләрнең башы нәкъ менә шуннан башлана да инде. Кешелеклелек төшенчәсе – зур мәгънәле төшенчә. Ул үзенә батырлыкны да, матурлыкны да, киң күңеллелекне дә, ярдәмчеллекне дә һәм тагын бик күп әйбәт сыйфатларны сыйдыра. Без бер вакытта да әйбәт булудан, кешелекле булудан, нечкә күңелле булудан курыкмасак иде.

Тормыш безне һәр көн сыный, кайвакыт утлы табада биетә. Алдыбызга куйган күп кенә сорауларын кайвакыт без үзебез дә белмибез. Намусыбызга тугры булсак, без ул сынауларны җиңеп чыгарбыз, халкыбыз күзенә, ата-аналарыбыз күзенә, бездән зур эшләр көткән кешеләр күзенә гел туры карый алырбыз. Шул вакытта бездән батыр кешеләр чыгар (Ф. Яруллин “Яз сулышы”әсәреннән)

**7.1. Исходя из содержания назовите текст (макс. б. -2).**

*Батырлыкның нигезләре*

**7.2. В каждом смысловом абзаце подчеркните выражение, предложение выражающие суть, смысл данного абзаца** (по 2 б., макс.б. – 12).

**7.3.Выпишите из последнего абзаца текста фразеологизмы. Составьте с ними свои предложения** (макс.б. – 6.

*утлы табага биетә*

*кешеләр күзенә гел туры карый*

**7.4. Кешелеклелек төшенчәсе – зур мәгънәле төшенчә. В 8 – 10 предложениях выразите свое отношение к данному понятию** ( по 2 б., макс.б. – 20).

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

_